МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от 14.09.2018 № 459

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 9 мартындагы 94 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкалага үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 9 мартындагы 94 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкалага үзгәрешләр кертергә.

2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге мөдире Н.Н. Доброхотовка әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве уздырырга.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 9 мартындагы
94 нче номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2018 елның 14 сентябрьдәге
459 нчы номерлы боерыгы редакциясендә)

**Татарстан Республикасы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкала**

| № т/с | Критерийлар / параметрлар | Күрсәткеч | Баллар саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Ачык конкурс үткәрү турында хәбәрне Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырган датага кадәрге ел дәвамында кешеләр үлеменә яисә гражданнарның сәламәтлегенә зыян салуга китергән һәм юридик зат, индивидуаль эшкуар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар яисә аларның хезмәткәрләре гаебе белән килеп чыккан юл-транспорт һәлакәтләре саны (хәбәр урнаштырылган датага кадәрге ел дәвамында пассажирларның гомеренә, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян китергән өчен юридик затның, индивидуаль эшкуарның яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләрендә каралган транспорт чараларының уртача саныннан чыгып исәпләнә).* | 0 | 0 |
| | | 0,01 – 0,5 | -2 |
| | | 0,51 - 1 | -4 |
| | | 1,01 - 2 | -6 |
| | | 2,01 – 2,5 | -8 |
| | | 2,51 һәм артыграк | -10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Юридик затның, индивидуаль эшкуарның яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның даими рәвештә пасажирлар йөртү һәм багаж ташу тәҗрибәсе (үтәлгән дәүләт контрактлары яисә муниципаль контрактлар турында белешмәләр, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында таныклыкларның күчермәләре, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары яисә җирле үзидарә органнары белән төзелгән шартнамәләр, Татарстан Республикасы субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган башка документлар белән расланган булырга тиеш)** | 5 ел һәм артыграк | 10 |
| | | 3 елдан 5 елга кадәр | 8 |
| | | 2 елдан 3 елга кадәр | 6 |
| | | 1 елдан 2 елга кадәр | 4 |
| | | 1 елдан кимрәк | 2 |
| 3. | Юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен тәкъдим итә торган транспорт чараларының пассажирлар йөртү һәм багаж ташу сыйфатына тәэсир итә торган характеристикалары | | |
| 3.1. | Түбән идән булу (һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 10 |
| | | Булмау | 0 |
| 3.2. | Электрон мәгълүмат таблосы булу (һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 5 |
| | | Булмау | 0 |
| 3.3. | Салонда һава температурасын тикшереп тору системасы булу (һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 5 |
| | | Булмау | 0 |
| 3.4. | Транспортта йөргән өчен карта белән түләү системасы булу (һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 10 |
| | | Булмау | 0 |
| 3.5. | Мотор өчен газ ягулыгын куллану җайланмасы булу (һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 10 |
| | | Булмау | 0 |
| 3.6. | Инвалид пассажирларны йөртү өчен җайланмалар булу (һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 10 |
| | | Булмау | 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.7. | Кондиционер булу<br>(һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 1 |
| | | Булмау | 0 |
| 3.8. | Техник структура:<br><br>Эшләү өчен Лотка туры килә торган, таләп ителә торган класслы хәрәкәт составы булу (һәрбер транспорт чарасы өчен) | Булу | 5 |
| | | Булмау | 0 |
| 3.9. | Ачык конкурс үткәрү турында хәбәрнамәдә һәм конкурс документациясендә хәрәкәт составына карата бәян ителгән  таләпләргә туры килә торган хәрәкәт составы булу: | ташучы милкендә (һәрбер транспорт чарасы өчен) | 15 |
| | | законлы булган башка нигездә (һәрбер транспорт чарасы өчен) | 10 |
| | | ачык конкурс үткәрү турында хәбәрнамәдә һәм конкурс документациясендә хәрәкәт составына карата бәян ителгән таләпләргә туры килә торган хәрәкәт составын заявкалы конвертларны ачкан көннән алып унбиш көннән дә артык булмаган вакытта сатып алу һәм (яисә) кайтару йөкләмәләрен раслый торган документлар булу | 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.10. | Реаль вакыт режимында мониторинглау өчен транспорт чараларының ЕГИС ГЛОНАСС+112 системасында булуын тәэмин итү. | Булу | 10 |
| | | Булмау | 0 |
| 4. | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык гамәлдә булган чорда даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен транспорт чараларын эксплуатацияләүнең максималь срогы (һәрбер транспорт чарасы өчен) | 0 – 5 ел (5 елны кертеп) | 10 |
| | | 6 – 10 ел (10 елны кертеп) | 5 |
| | | 11 ел һәм артыграк | 1 |

*Транспорт чараларының әлеге Шкаланың 1 пунктында каралган критерийны ачыклаганда исәпкә алына торган уртача саны ачык конкурста катнашуга заявкада күрсәтелгән транспорт чараларына карата граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре хәбәрнамә урнаштырылган датага кадәрге ел дәвамында гамәлдә булган көннәрнең гомуми санының тиешле елдагы көннәр санына чагыштырмасыннан чыгып исәпләнә.

** Әлеге критерий юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга карата – алар муниципальара маршрутлар буенча даими даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырган тулы еллар санынннан чыгып, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга карата һәрбер катнашучы муниципальара маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырган тулы елларның уртача арифметик санынннан чыгып исәпләнә.